*Алдагы очракларда нәрсә эшләргә:*



## 1. Сезнең йортыгызга су басу куркынычы янаганда:

· электр энергиясен сүндерегез;

· җылыту мичләрендәге утны сүндерегез;

· йорт алдындагы барлык беркетелмәгән әйберләрне кертеп куегыз яки беркетегез;

· барлык кыйммәтле әйберләрне чарлакка яки өске катларга меңгерегез;

· аскы каттагы ишекләрне һәм тәрәзәләрне фанера яки агач такталар белән кадаклап куегыз (бу тәрәзә пыялаларын йөзүче чүп-чардан һәм бүрәнәләрдән саклап калачак);

· торак йортларны һәм милекне иминиятләштерү турында алдан кайгыртыгыз.

## 2. Эвакуация башлангач:

· тынычлыкны саклагыз;

· күршеләрне кисәтегез, балаларга, инвалидларга һәм өлкәннәргә ярдәм итегез;

· акча һәм документларны полиэтиленга төрегез;

· үзегез куллана торган даруларны әзерләгез;

· үзегез белән мендәр тышы һәм җәймә, бәдрәф кирәк-яраклары, җылы һәм җиңел әйберләрне генә алыгыз;

· коткаручылар киңәшләрен төгәл үтәгез;

· ярдәм килгәнче яки су дәрәҗәсе төшкәнче йортның өске катларнда һәм түбәсендә булыгыз;

· сезне тизрәк табу максатларында сигнал бирегез: якты вакытта – ак яки төсле япма белән болгап яки аны элеп куеп, караңгы вакытта – ут сигналы яки вакыт-вакыт тавыш белән.

## 3. Су дәрәҗәсе күтәрелгәндә:

· Мөмкин кадәр күбрәк суда батмый торган әйберләр җыярга (мөмкин булганда, бергә бәйләп) тырышыгыз. Бу – машина камералары, бүрәнәләр, өстәлләр булырга мөмкин. Һәрхәлдә, кием астына капкачлары яхшы ябылган пластик шешәләр кыстырыгыз.



## 4. Су дәрәҗәсе түбәнәйгәндә:

· йортка керү алдыннан йортның төп корылмалары төзек хәлдә икәнен ачыклагыз;

· йортны җилләтегез, газ, электр һәм су белән куллану белгечләр газ чыгу куркынычы булмауга инангач кына рөхсәт ителә;

· суга ләккән ризыкны ашамагыз;

· коены куллану алдыннан коткаручыларны яки санитария хезмәткәрләрен суның сыйфатын тикшерүен сорагыз.

## Җәмәгать!

**Теләсә кайсы шартларда үз-үзегезне кулда тотыгыз, паникага бирелмәгез, тиз эш итегез, әмма уйлап һәм ыгы-зыгыдан башка!**

**Исегезгә төшерәбез, ТР ГТХМда һәлакәтләр турында хәбәрләрне кабул итү өчен түбәндәге телефон номерлары бар:**

**стационар телефоныннан:**
**101, 288-46-46, 112**

**мобиль телефоныннан**
**112 номерына шалтрату бушлай**

### ЭКСТРЕМАЛЬ ХӘЛЛӘРДӘ ЯРДӘМ СОРАП КАЯ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘРГӘ БУЛА

| | |
|---|---|
| Бердәм коткару хезмәте телефоны (мобиль һәм стационар телефоныннан) | **112** |
| ГТХМ һәм янгын хезмәте | **101** |
| Полиция | **102** |
| Ашыгыч медицина ярдәме | **103** |
| Горгаз | **104** |
| ТР ГТХМ оператив дежуры | **288-46-46** |
| Казан шәһәре гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр эшләре идарәсе оператив дежуры | **264-29-00** |
| Һәлакәтләр медицинасы үзәгенең оператив дежуры | **293-49-95** |
| Эзләү-коткару хезмәте | **272-43-12** |

420033, Татарстан Республикасы,
Казан ш., Коләхмәтов ур., 5А йорт.
тел.: (8432) 554-48-09

**Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча Укыту-методик үзәгенең әзерләү бүлеге**

**БЕЛЕШМӘЛЕК**

# Су басу вакытында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре



Казан ш.
2021